| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 2 апрель г.Казань № 212

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2018 ел, 14 июнь, 482 нче; 2018 ел, 15 июнь, 486 нчы; 2018 ел, 16 ноябрь, 998 нче; 2019 ел, 17 июль, 594 нче; 2019 ел, 28 август, 715 нче; 2019 ел, 22 октябрь, 952 нче, 2019 ел, 06 декабрь, 1110 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан

Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның җиденче абзацында «комплекслы тернәкләндерү белгече (реабилитолог)» сүзләреннән соң «, «социаль тернәкләндерү буенча белгеч» сүзләрен өстәргә;

6.2 пунктта «комплекслы тернәкләндерү белгече (реабилитолог)» сүзләреннән соң «, социаль тернәкләндерү буенча белгеч» сүзләрен өстәргә;

6.4.2 пунктчасында:

2 нче таблицаның 2 нче графасында 2 пунктта «комплекслы тернәкләндерү белгече (реабилитолог)» сүзләрен «комплекслы тернәкләндерү белгече (реабилитолог)», «социаль тернәкләндерү буенча белгеч» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче таблицада:

2 нче графаның 1 пунктында «, социаль реабилитация буенча белгеч» сүзләрен өстәргә;

3 нче графаның 1 пунктында «, социаль тернәкләндерү буенча белгеч вазыйфасын» сүзләрен өстәргә;

6.2.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2.5. Премияләр һәм башка бүләкләү түләүләре социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеле бер вакыт аралыгында (бер ай, квартал, бер ел), шул исәптән бер мәртәбә, хезмәтнең нәтиҗәле нәтиҗәләренә ирешүне стимуллаштыру, халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасы дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Указында билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең фактта ирешелгән дәрәҗәсен саклауны тәэмин итүне исәпкә алып, юбилей даталарына, аеру билгеләрен, рәхмәт хатларын, дәүләт бүләкләрен алуга һәм оешманың локаль актларында һәм коллектив шартнамәләрендә билгеләнгән башка нигезләрдә билгеләнә.

Премияләр һәм башка бүләкләү түләүләре «гаилә белән эшләү буенча белгеч», «комплекслы тернәкләндерү белгече (реабилитолог)» һәм «социаль тернәкләндерү буенча белгеч» вазыйфаларын башкаручы хезмәткәрләргә билгеле бер вакыт аралыгында (бер ай, квартал, бер ел), шул исәптән бер мәртәбә, юбилей даталары, аеру билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алуга һәм оешманың локаль норматив актларында һәм коллектив шартнамәләрендә билгеләнгән башка нигезләрдә билгеләнә.

Премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре күләмнәре, тәртибе һәм аларны башкару шартлары Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтү дәүләт оешмаларының, социаль яклау дәүләт учреждениеләренең локаль актларында һәм күмәк шартнамәләрдә билгеләнә.»;

6.2.6 пунктчада «эшләүче хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә» сүзләрен «эшләүче хезмәткәрләргә» сүзләренә алмаштырырга;

6.8.9 пунктчадагы 19 нчы таблицаның 2 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2. | «Сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыручы учреждениеләрдә өченче баскыч белгечләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| 2.1. | Инвалидларның һөнәри юнәлеше буенча белгеч | 50 |
| 2.2. | Социаль эш буенча белгеч | 50 |
| 2.3. | Гаилә белән эшләү буенча белгеч | 50 |
| 2.4. | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор-методист | 50 |
| 2.5. | Медицина психологы | 55 |
| 2.6. | Инвалидларны реабилитацияләү буенча белгеч | 55 |
| 2.7. | Комплекслы тернәкләндерү буенча белгеч (реабилитолог) | 55 |
| 2.8. | Социаль тернәкләндерү буенча белгеч | 55 |
| 2.9. | Инвалидларны тернәкләндерүнең техник чаралары буенча инженер | 55 |
| 2.10. | Инвалидларны һөнәри тернәкләндерү буенча консультант | 60»; |

6.9 пунктта:

беренче абзацта «һәм «комплекслы тернәкләндерү белгече (реабилитолог)» сүзләрен «, «комплекслы тернәкләндерү белгече (реабилитолог)» һәм «социаль тернәкләндерү буенча белгеч» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацта «гаилә белән эшләү буенча белгеч» сүзләреннән соң «комплекслы тернәкләндерү белгече (реабилитолог)» һәм «социаль тернәкләндерү буенча белгеч» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымтада:

исемендә «гаилә белән эшләү буенча белгеч» сүзләреннән соң «комплексы тернәкләндерү белгече (реабилитолог)», «социаль тернәкләндерү буенча белгеч» сүзләрен өстәргә;

2 графаның 1.2 пунктчасында «гаилә белән эшләү буенча белгеч» сүзләреннән соң «комплексы тернәкләндерү белгече (реабилитолог), социаль тернәкләндерү буенча белгеч» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта исемендә «һәм социаль хезмәтләр күрсәтелгәннән соң,» сүзләреннән соң «гаилә белән эшләү буенча белгеч», «комплексы тернәкләндерү белгече (реабилитолог)» һәм «социаль тернәкләндерү буенча белгеч»,» сүзләрен өстәргә.

2. Бу карарның гамәле 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин